**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ ИВАШКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

ул.Центральная, д.1а, с.Ивашкино, 423113

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**ИВАШКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ**

Үзек урамы, 1а йорт, Ивашкино авылы, 423113

тел./факс (84396) 3-82-19 email: Iva.Cmn2@tatar.ru

**№ 146** **28 октябрь 2019 ел**

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИВАШКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы «Ивашкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасының Чирмешән муниципаль районының «Ивашкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Ивашкино авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы «Ивашкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 22 статьяга киләсе пунктны өстәргә: «3.1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясында каралган гражданнар җыены анда торак пункт яки җирлектә сайлау хокукына ия яшәүчеләрнең яртысыннан артыграгы катнашса вәкаләтле дип исәпләнә. Торак пунктта әлеге торак пунктта сайлау хокукына ия булган яртысыннан артыграк яшәүчеләрнең бер үк вакытта бергә булу мөмкинлеге булмаса, гражданнар җыены әлеге Устав нигезендә этаплап, гражданнар җыенын үткәрү турында карар кабул ителгән көннән алып бер айдан да артмаган вакыт эчендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлеге торак пунктларында гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмә белән расланган тәртиптә үткәрелә. Шул ук вакытта элек гражданнар җыенында катнашкан затлар тавыш бирүдә киләсе этапларда катнашмый. Гражданнар җыены карары кабул ителгән дип санала, әгәр җыенда катнашучыларның яртысыннан артыгы аның өчен тавыш биргән булса».

1.2. 49 статьяның 2 өлешендәге 19 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә: «Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 2300-1

номерлы Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыра».

1.3. Статью 87 статьяны яңа редакциядә бәян итәргә: «1. Үзара салым акчалары дигәндә, гражданнарның җирле әһәмияттәге конкрет мәсьәләләрне хәл итү өчен бер тапкыр башкарыла торган түләүләре аңлашыла. Гражданнарның үзара салымы күләме, авыл җирлегендә (җирлек составына керүче торак пунктта) яшәүчеләрнең гомуми санынннан 30 проценттан артмаган түләү күләме кимeтелергә мөмкин булган аерым категория гражданнардан тыш, барлык авыл (җирлек составына керүче торак пункт) халкы өчен дә абсолют күләмдә тигез билгеләнә.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән гражданнар тарафыннан бер тапкыр бирелә торган түләүләрне кертү һәм куллану мәсьәләләре җирле референдумда, ә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясындагы 1 өлешенең 4.1 пунктында каралган очракларда гражданнар җыенында хәл ителә.

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

3. Дәүләт теркәвеннән соң әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга..

4. Әлеге карар «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясындагы 8 өлеше, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы «Ивашкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 87 статьясындагы 2 өлеше нигезләмәләрен исәпкә алып, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Ивашкино авыл җирлеге
Башлыгы, Совет рәисе Н.Н.Ефимов